**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 10 мартындагы 645 номерлы карары**

**Җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалану мөмкинлеген тәэмин итү белән бәйле рәвештә аерым категориягә караган гражданнарны бердәм электрон исемле социаль юл билетлары (ташламалы транспорт картасы) буенча йөртүдән алынып бетмәгән керемнәрен каплау максатыннан оешмаларга Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы «Юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне һәм әлеге субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар алучыларны сайлап алуны үткәрүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләрне раслау турында»гы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 20 мартындагы 210 номерлы «Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы территориясендә аерым категориягә караган гражданнарга җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субсидияләр бирү тәртибен раслау турында»гы карары, Казан шәһәре Думасының 2024 елның 18 декабрендәге 3-35 номерлы «2025 елга һәм 2026 һәм 2027 елларның план чорына Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турында»гы нигезендә **карар бирәм:**

1. Җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалану мөмкинлеген тәэмин итү белән бәйле рәвештә аерым категориягә караган гражданнарны бердәм электрон исемле социаль юл билетлары (ташламалы

транспорт картасы) буенча йөртүдән алынып бетмәгән керемнәрен каплау максатыннан оешмаларга Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.

2. Җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итү белән бәйле рәвештә гражданнарның аерым категорияләрен бердәм электрон исемле социаль йөртү билетлары (ташламалы транспорт картасы) буенча йөртүдән алып бетермәгән керемнәрен каплау максатыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү буенча Казан шәһәре Башкарма комитетының вәкаләтле органы итеп Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитетын билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 10 мартындагы
645 номерлы карарына
кушымта

**Җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалану мөмкинлеген тәэмин итү белән бәйле рәвештә аерым категориягә караган гражданнарны бердәм электрон исемле социаль юл билетлары (ташламалы транспорт картасы) буенча йөртүдән алынып бетмәгән керемнәрен каплау максатыннан оешмаларга Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе**

1. Әлеге Тәртип җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалану мөмкинлеген тәэмин итү белән бәйле рәвештә аерым категориягә караган гражданнарны бердәм электрон исемле социаль юл билетлары (ташламалы транспорт картасы) буенча йөртүдән алынып бетмәгән керемнәрен каплау максатыннан оешмаларга Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр (алга таба – субсидияләр) бирү процедурасын билгели.

2. Субсидия бирүнең максаты – җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалану мөмкинлеген тәэмин итү белән бәйле рәвештә аерым категориягә караган гражданнарны бердәм электрон исемле социаль юл билетлары (ташламалы транспорт картасы) буенча йөртүдән алынып бетмәгән керемнәрен каплау. Татарстан Республикасында аерым категориягә караган гражданнар өчен транспорт хезмәтләреннән бертигез файдалану Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 7 апрелендәге 161 номерлы «Татарстан Республикасында бердәм айлык социаль юл билеты һәм балаларга бердәм айлык социаль юл билеты бирү тәртибен раслау турында»гы карары нигезендә кертелгән бердәм айлык социаль юл билетларын һәм балалар өчен бердәм айлык социаль юл билетларын гамәлгә ашыру юлы белән тәэмин ителә.

3. Субсидияләр Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитеты (алга таба – Вәкаләтле орган) тарафыннан тиешле финанс елына һәм план чорына Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турында Казан шәһәре Думасы карарында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә һәм әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатка субсидияләр бирү өчен билгеләнгән тәртиптә бюджет чараларын алучы буларак Вәкаләтле органга җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

4. Тиешле финанс елына Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында каралган субсидияләр Вәкаләтле органның Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының Казан шәһәре территориаль бүлекчәсендә ачылган шәхси счетында исәпкә алына.

5. Субсидия турында белешмәләр Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – бердәм портал, «Интернет» челтәре) «Бюджет» бүлегендә урнаштырыла.

6. Субсидия алучылар Вәкаләтле орган тарафыннан сайлап алуда катнашу өчен оешмалар тарафыннан җибәрелгән тәкъдимнәрне (гаризаларны) соратып алу юлы белән уздырыла торган сайлап алу нәтиҗәләре буенча (алга таба – гаризалар, сайлап алуда катнашучылар), сайлап алуда катнашучыларның категорияләргә, сайлап алу критерийларына һәм гаризаларның керү чиратына туры килүеннән чыгып билгеләнә.

7. Сайлап алу критерийлары түбәндәгеләр:

- оешма Казан шәһәренең муниципаль маршрутлары буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне башкаруга муниципаль контрактлар (шартнамәләр) һәм (яисә) даими рәвештә пассажирлар йөртү маршруты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклык һәм шәһәр яны юлларының муниципальара маршрутлары буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашырганда даими рәвештә пассажирлар йөртү маршруты картасы нигезендә Казан шәһәрендә гомуми кулланылыштагы транспортта пассажирлар йөртү буенча эшчәнлек алып бара;

- оешма Казан шәһәре халкын йөртүне гамәлгә ашыру өчен матди-техник чараларга ия;

- оешма ташламалы категориядәге гражданнарны ташый.

8. Вәкаләтле органның сайлап алуда катнашучылар белән сайлап алу һәм үзара хезмәттәшлеге «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең интеграцияләнгән мәгълүмат системасында (алга таба – «Электрон бюджет» системасы) гамәлгә ашырыла.

9. Сайлап алуда катнашучыларның «Электрон бюджет» системасына керү мөмкинлекләре «Электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификацияләүнең һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып гамәлгә ашырыла.

10. Сайлап алуда катнашучы сайлап алуны үткәрү көненә кадәр кимендә 30 календарь көн кала түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

- чит ил, шул исәптән Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория теркәлү урыны булып торган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (Россия Федерациясе законнары белән башкасы каралмаган очракта) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендә оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яисә) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашуы белән гамәлгә ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

- экстремистик эшчәнлеккә яки терроризмга катнашлары турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

- БМО Уставының VII бүлеге, БМО Куркынычсызлык советы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру кысаларында яки БМО Куркынычсызлык советы карарлары нигезендә махсус төзелгән оешмалар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән бәйле яисә массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

- әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максат өчен Казан шәһәре муниципаль берәмлеге хокукый акты нигезендә, башка норматив хокукый актларына таянып, субсидия бирү планлаштырыла торган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан акчалар алмый;

- «Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында»гы федераль закон нигезендә чит ил агенты булып тормый;

- бердәм салым счетында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычы юк яисә Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пункты белән билгеләнгән күләмнән артмый;

- юридик зат булып торган сайлап алуда катнашучы (субсидия алучы) үзгәртеп оештыру (субсидия алучы (сайлап алуда катнашучы) булып торган

юридик затка башка юридик затны кушу формасында гамәлгә ашырылган үзгәртеп оештырудан тыш), ябылу процессында түгел, аңа карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, субсидия алучының (сайлап алуда катнашучының) эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән каралган тәртиптә туктатылмаган, ә шәхси эшмәкәр булып торган субсидия алучы (сайлап алуда катнашучы) шәхси эшмәкәр сыйфатында эшчәнлеген туктатмаган;

- дисквалификацияләнгән затлар реестрында юридик зат булып торган субсидия алучының (сайлап алуда катнашучының) дисквалификацияләнгән җитәкчесе, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бер кеше башкара торган башкарма орган функциясен үтәүче зат яисә баш бухгалтеры (булган очракта) турында, шәхси эшмәкәр турында һәм субсидия алучы (сайлап алуда катнашучы) булган товар җитештерүче, эш башкаручы, хезмәт күрсәтүче физик зат турында белешмәләр юк;

- Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча түләү вакыты узган бурычы, шул исәптән Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты алдында акчалата йөкләмәләр буенча түләү вакыты узган (җайга салынмаган) башка бурычы юк;

Сайлап алуда катнашучының әлеге пунктның таләпләренә туры туры килү-килмәвен карап тикшерү сайлап алуны тәэмин итүче дәүләт мәгълүмат системалары (алга таба – дәүләт мәгълүмат системасы) мәгълүматлары нигезендә, «Электрон бюджет» системасында, шул исәптән ведомствоара электрон багланышларның бердәм системасын кулланып (автоматик тикшерүнең техника мөмкинлеге булганда) автомат рәвештә гамәлгә ашырыла.

«Электрон бюджет» системасында автомат тикшерүне гамәлгә ашыруның техник мөмкинлеге булмаган очракта, катнашучының әлеге пункт таләпләренә туры килү-килмәвен раслау «Электрон бюджет» системасында веб-интерфейсның тиешле экран формаларын тутыру юлы белән күрсәтелгән таләпләргә туры килүе турында тамгаларны сайлап алуда катнашучы тарафыннан электрон рәвештә билгеләп кую юлы белән башкарыла.

Билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәү өчен җаваплылыкны субсидия алучы йөртә.

11. Сайлап алуны уздыру турында игълан Вәкаләтле орган тарафыннан «Электрон бюджет» системасында веб-интерфейсның тиешле экран формаларын тутыру юлы белән электрон рәвештә төзелә, Вәкаләтле орган җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, бердәм порталда төзелгән көннән алып бер календарь көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарыла.

Игълан үз эченә түбәндәге мәгълүматны ала:

- сайлап алуны уздыру вакыты;

- сайлап алуда катнашучыларның гаризаларын кабул итү башлану һәм тәмамлану көннәре һәм вакыты, шул ук вакытта гаризаларны кабул итү тәмамлану көне сайлап алуны уздыру турында игълан урнаштырылган көннән соң килгән биш календарь көннән дә иртәрәк була алмый;

- Вәкаләтле органның атамасы, урнашу урыны, почта адресы, электрон почта адресы;

- Вәкаләтле орган сайтының домен исеме һәм (яисә) челтәр адресы, һәм (яисә) сәхифәләр күрсәткечләре;

- әлеге Тәртипнең 10 пункты һәм сайлап алуда катнашучылар тарафыннан күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеге нигезендә сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләр;

- әлеге Тәртипнең 7 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучылар туры килергә тиешле сайлап алу критерийлары;

- сайлап алуда катнашучылар тарафыннан гаризалар тапшыру тәртибе һәм сайлап алуда катнашучылар тарафыннан әлеге Тәртипнең 13, 14 пунктлары нигезендә тапшырыла торган гаризалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләр;

- әлеге Тәртипнең 16 пункты нигезендә гаризаларны кире алу тәртибе, гаризаларны кире кайтару, шул исәптән гаризаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгеләү тәртибе, гаризаларга үзгәрешләр кертү тәртибе;

- әлеге Тәртипнең 18-22 пунктлары нигезендә гаризаларны карап тикшерү кагыйдәләре;

- гаризаларны кире кагу тәртибе, шулай ук аларны әлеге Тәртипнең 22 пункты нигезендә кире кагу нигезләре турындагы мәгълүмат;

- әлеге Тәртипнең 16 пункты нигезендә эшләп бетерүгә гаризаларны кире кайтару тәртибе;

- әлеге Тәртипнең 41 пунктында билгеләнгән субсидия күләмен исәпләү тәртибе;

- әлеге Тәртипнең 17 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны уздыру турындагы белдерү нигезләмәләре буенча аңлатмалар бирү тәртибе, аңлатмалар бирүнең башлану һәм тәмамлану көне;

- әлеге Тәртипнең 29 пункты нигезендә сайлап алуның җиңүчесе (җиңүчеләре) субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) кул куярга тиешле вакыт;

- әлеге Тәртипнең 32 пункты нигезендә сайлап алуның җиңүчесен (җиңүчеләрен) килешү төзүдән баш тарткан (баш тартканнар) дип тану шартлары;

- бердәм порталда һәм Вәкаләтле органның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында https://kzn.ru/meriya/ispolnitelnyy-komitet/komitet-po-transportu/konkursy/ (алга таба – Вәкаләтле органның рәсми сайты) сайлап алуга нәтиҗә ясау беркетмәсен урнаштыру вакыты, ул сайлап алуда җиңүчене билгеләгән көннән соң килгән 14 календарь көннән дә соң була алмый;

- әлеге Тәртипнең 38 пунктында билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе.

Сайлап алуны уздыру турында игълан итүгә үзгәрешләр кертү сайлап алуда катнашучыларның гаризаларын кабул итеп алу тәмамланган датадан соңга калмыйча түбәндәге шартлар нигезендә гамәлгә ашырыла:

- сайлап алуда катнашучылар тарафыннан гаризалар бирү вакыты, шундый үзгәрешләр кертелгән көннең икенче көненнән башлап гаризаларны кабул итү тәмамланган датага кадәр әлеге срок кимендә өч календарь көн тәшкил итәрлек итеп озайтыла;

- сайлап алуны уздыру турында игъланга үзгәрешләр кертелгәндә, сайлап алу ысулын үзгәртү рөхсәт ителми;

- гаризалар кабул итә башлау датасы башланганнан соң сайлап алуны уздыру турында игълан итүгә үзгәрешләр кертелгән очракта, сайлап алуны уздыру турында игълан итүгә сайлап алуда катнашучыларның гаризаларга үзгәрешләр кертү хокукын күздә тоткан нигезләмә кертелә;

- гариза биргән сайлап алуда катнашучыларга, сайлап алуны үткәрү турында игъланга үзгәрешләр кертелгән көннең икенче көненнән дә соңга калмыйча, «Электрон бюджет» системасы аша сайлауларны уздыру турында игъланга үзгәрешләр кертү хакында хәбәр ителә.

12. Бердәм порталда сайлап алу үткәрүне гамәлдән чыгару турында Вәкаләтле орган тарафыннан игълан урнаштыру сайлап алуда катнашучыларның гаризаларын бирү срогы тәмамланганчы бер эш көненнән дә соңга калмыйча рөхсәт ителә.

Сайлап алу үткәрүне гамәлдән чыгару турында игълан электрон рәвештә «Электрон бюджет» системасында веб-интерфейсның тиешле экран формаларын тутыру юлы белән төзелә, Вәкаләтле орган (ул вәкаләт биргән зат) җитәкчесенең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, бердәм порталда урнаштырыла һәм сайлап алуны гамәлдән чыгару сәбәпләре турындагы мәгълүматны үз эченә ала.

Сайлап алуны гамәлдән чыгару очрагы булып Вәкаләтле органның әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатка җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын кире кайтарып алу тора.

Сайлап алуда катнашучы гариза бирүчеләргә сайлап алу үткәрүне гамәлдән чыгару турында мәгълүматны «Электрон бюджет» системасы аша җиткерәләр.

Сайлап алу бердәм порталда аны гамәлдән чыгару турында игълан урнаштырылган көннән гамәлдән чыгарылган дип санала.

Әлеге пунктның беренче абзацы нигезендә сайлап алу үткәрүне гамәлдән чыгару вакыты тәмамланганнан соң һәм сайлап алуда җиңүче белән килешү төзелгәнгә кадәр Вәкаләтле орган Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 401 статьясындагы 3 пункты нигезендә каршы тора алмаслык хәл барлыкка килгән очракта гына сайлап алуны гамәлдән чыгарырга мөмкин.

13. Сайлап алуда катнашучы, сайлап алуны үткәрү турында игъланда күрсәтелгән вакыт эчендә, электрон рәвештә «Электрон бюджет» системасындагы веб-интерфейсның тиешле экран формаларын тутыру юлы белән гариза формалаштыра һәм «Электрон бюджет» системасына түбәндәге документларның электрон күчермәләрен (сканерлау юлы белән электрон формага үзгәртелгән кәгазь чыганактагы документларны) тапшыра:

- лицензияләнә торган эшчәнлек төрләре гариза бирүче тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырылганда, хуҗалык эшчәнлеген башкаруга лицензия;

- Казан шәһәренең муниципаль маршрутлары буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга муниципаль контрактлар (килешүләр) һәм (яисә), шәһәр яны муниципаль маршрутлары буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда, даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклыкларның һәм даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру маршрутлары карталарының булуын раслый торган документ;

- шәһәр пассажир транспортында йөргән өчен түләүнең автоматлаштырылган системасы операторы белән төзелгән килешү;

- сайлап алуда катнашучының бердәм салым счетында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычы булмавын яисә Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пункты белән билгеләнгән күләмнән артмавын раслый торган документлар.

Юридик зат әлеге пунктта күрсәтелгән документларга өстәмә рәвештә түбәндәгеләр тапшырыла:

а) гамәлгә кую документларының һәм аларга кертелгән барлык үзгәрешләрнең күчермәләре;

б) җитәкче вәкаләтләрен раслый торган документлар.

Шәхси эшмәкәр тарафыннан әлеге пунктта күрсәтелгән документларга өстәмә рәвештә шәхси эшмәкәр паспортының күчермәсе (беренче янәшә битләр һәм теркәлү тамгасы булган янәшә битләр), шәхси эшмәкәрне дәүләт теркәвенә алу турында таныклыкның күчермәсе (яисә Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестры теркәү кәгазенең күчермәсе) тапшырылалар.

Гаризада түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

- сайлап алуда катнашучы турында мәгълүмат һәм документлар;

- сайлап алуда катнашучының тулы һәм кыскартылган исеме;

- сайлап алуда катнашучының төп дәүләт теркәве номеры;

Салым түләүченең идентификация номеры

- салым органында исәпкә кую көне һәм коды;

- юридик зат адресы;

- юридик яктан әһәмиятле хәбәрләр җибәрү өчен элемтә телефоны номеры, почта адресы һәм электрон почта адресы;

- сайлап алуда катнашучының җитәкчесе турында мәгълүмат (фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), салым түләү идентификация номеры, вазифасы);

- сайлап алуда катнашучыларның гамәлгә кую документлары нигезендә сайлап алуда катнашучы гамәлгә ашырырга хокуклы төп һәм өстәмә эшчәнлек төрләре исемлеге;

- субсидияне күчерү өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә счетлар турында, шулай ук килешүне имзалауга Вәкаләтле зат турында мәгълүмат;

- сайлап алуда катнашучы турында, сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелгән гариза, шулай ук «Электрон бюджет» системасының тиешле экран формаларын тутыру юлы белән бирелә торган субсидияне тиешле сайлап алуга һәм аның нәтиҗәсенә бәйле сайлап алуда катнашучы турында башка мәгълүматны «Интернет» челтәрендә бастырып чыгару (урнаштыру) ризалыгы.

Вәкаләтле органга, сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслау максатларында документлар һәм мәгълүмат бирүне, ведомстволарара электрон хезмәттәшлек кысаларында Вәкаләтле органның файдалана алуы мөмкинлеге булган дәүләт мәгълүмат системаларында тиешле мәгълүмат булган очракта (сайлап алуда катнашучы күрсәтелгән документларны һәм мәгълүматны Вәкаләтле органга үз инициативасы белән

тапшырырга әзер булган очрактан тыш), сайлап алуда катнашучыдан таләп итү тыела.

Гаризага кертелә торган документларның һәм материалларның электрон күчермәләре документны тулысынча яисә аның фрагментын мәгълүматны карауның һәркем файдалана алырлык программа тәэминаты чаралары белән карау мөмкинлеген тәэмин итә торган киң таралган ачык форматларга ия булырга һәм аларның эчтәлеге белән махсус программа яисә технологик чаралардан башка танышырга мөмкинлек бирми торган чаралар белән шифрланган яисә якланган булырга тиеш түгел.

14. Гариза сайлап алуда катнашучы җитәкчесенең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән яисә ул вәкаләт биргән зат тарафыннан имзалана.

Россия Федерациясе законнары нигезендә гаризада булган мәгълүматның һәм документларның тулылыгы һәм дөреслеге өчен, шулай ук аларны вакытында тапшыру өчен сайлап алуда катнашучы җаваплы була.

15. Сайлап алуда катнашучы тарафыннан имзаланган гаризага «Электрон бюджет» системасында теркәлү номеры куелган көн сайлап алуда катнашучының гариза тапшыру датасы итеп дип санала.

16. Сайлап алуда катнашучы гаризаны сайлап алуны уздыру тәмамланган датага кадәр теләсә кайсы вакытта кире алырга хокуклы. Кирәк булганда сайлап алуда катнашучы, гаризалар бирү өчен билгеләнгән вакыт эчендә, кабат гариза бирергә хокуклы.

Сайлап алуда катнашучы тарафыннан гаризага үзгәрешләр кертү яисә гаризаны кире кайтарып алу сайлап алуда катнашучының гариза бирү тәртибенә охшаш тәртиптә башкарыла.

Гаризаларны сайлап алуда катнашучыларга эшләп бетерү өчен кире кайтару каралмаган.

17. Сайлап алуның теләсә кайсы катнашучысы бердәм порталда сайлап алу үткәрелү турында игълан урнаштырылган көннән башлап гаризалар бирү тәмамланырга өч эш көненнән дә соңга калмыйча, «Электрон бюджет» системасында тиешле мөрәҗәгатне формалаштыру юлы белән Вәкаләтле органга сайлап алуны уздыру турында игълан итү нигезләмәләрен аңлату турында иң күбе өч сорау җибәрергә хокуклы.

Вәкаләтле орган күрсәтелгән игълан белән билгеләнгән вакытта сайлап алуны уздыру турында игълан итү нигезләмәләрен аңлатуны, гариза бирү тәмамланырга бер эш көненнән дә соңга калмыйча, «Электрон бюджет» системасында тиешле аңлатма бирү юлы белән җибәрә. Сайлап алуны уздыру

турындагы игълан нигезләмәләренең аңлатмалары аның асылын үзгәртергә тиеш түгел.

18. Вәкаләтле орган тарафыннан «Электрон бюджет» системасында гаризаларны карау Вәкаләтле органга гаризаларны карау өчен керү мөмкинлеге ачылганнан соң килүче 10 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Вәкаләтле органга «Электрон бюджет» системасына керү мөмкинлеге сайлап алуны үткәрү турындагы игъланда билгеләнгән гаризалар бирү вакыты тәмамланган көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча ачыла.

«Электрон бюджет» системасында Вәкаләтле орган тарафыннан гаризалар бирү вакыты тәмамланганчыга кадәрге көн билгеләнергә мөмкин, ул узганнан соң Вәкаләтле органга «Электрон бюджет» системасында сайлап алуда катнашучылар биргән гаризаларга керү мөмкинлеге ачыла.

19. Вәкаләтле орган сайлап алуны уздыру турында игълан итүдә билгеләнгән гаризаларны ачу көненнән соң килүче бер эш көненнән дә соңга калмыйча, сайлауда катнашу өчен килгән гаризалар турында түбәндәге мәгълүматны үз эченә алган гаризаларны ачу турында беркетмәгә имза сала:

а) гаризаны теркәү номеры;

б) гариза килү көне һәм вакыты;

в) сайлап алуда катнашучының тулы исеме;

г) юридик зат адресы.

20. Гаризаларны ачу беркетмәсе бердәм порталда автомат рәвештә төзелә һәм «Электрон бюджет» системасында Вәкаләтле орган җитәкчесенең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, шулай ук имза салынган көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча бердәм порталда урнаштырыла.

21. Сайлап алуны уздыру турында игълан итүдә күрсәтелгән таләпләргә туры килсә һәм гаризаны кире кагу өчен нигезләр булмаганда, гариза тиешле дип таныла.

Сайлап алуны уздыру турында игълан иткәндә күрсәтелгән таләпләргә гаризаның туры килүе турындагы карар Вәкаләтле орган тарафыннан сайлап алуда катнашучы тапшырган гариза составында бирелгән мәгълүматны һәм документларны тикшерү нәтиҗәләрен алу көненә кабул ителә.

22. Гаризаны карау стадиясендә аны кире кагу өчен нигезләр булып түбәндәгеләр тора:

а) сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 10 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

б) сайлап алуны үткәрү турында игълан итүдә күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

в) конкурста катнашучы тарафыннан тапшырылган гаризаларның һәм (яисә) документларның сайлап алуны уздыру турында игълан ителгән таләпләргә туры килмәве;

г) әлеге Тәртипнең 10 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслау максатларында сайлап алуда катнашучы тарафыннан гариза составында тапшырылган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы;

д) сайлап алуда катнашучының гаризалар бирү өчен билгеләнгән көннән һәм (яисә) вакыттан соң гариза тапшыруы;

23. Гаризаларны карау вакыты тәмамланган көннән алып бер эш көненнән дә соңга калмыйча, гаризаларны карау нәтиҗәләре буенча Вәкаләтле орган тарафыннан, кабул ителгән һәм каралган гаризаларның саны турында мәгълүматны, шулай ук һәр катнашучыга аның гаризасын тиешле дип тану турында яисә аның гаризасын кире кагу нигезләрен күрсәтеп, гаризаларны карау турында беркетмә төзелә.

24. Гаризаларны карау турында беркетмә гаризаларны карау нәтиҗәләре нигезендә бердәм порталда автомат рәвештә формалаштырыла һәм «Электрон бюджет» системасында Вәкаләтле орган (ул вәкаләт биргән зат) җитәкчесенең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, шулай ук аңа имза салынган көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча бердәм порталда урнаштырыла.

25. Түбәндәге очракларда сайлап алу узмаган дип таныла:

а) гаризалар бирү вакыты тәмамланганнан соң, бер гариза да бирелмәгән;

б) гаризаларны карау нәтиҗәләре буенча барлык гаризалар кире кагылган.

26. Кабул ителгән гаризаларны ранжирлау аларның керү чиратыннан чыгып гамәлгә ашырыла.

27. Әлеге Тәртипнең 7 һәм 10 пунктларында күрсәтелгән критерийларга һәм таләпләргә туры килә торган сайлап алуда катнашучылар сайлап алуның җиңүчеләре дип таныла.

28. Сайлап алу җиңүчесен сайлап алуны төгәлләү һәм ачыклау максатыннан сайлап алу йомгакларын ясау беркетмәсе төзелә. Сайлап алу йомгакларын ясау беркетмәсе сайлап алу җиңүчесен билгеләү нәтиҗәләре нигезендә бердәм порталда автомат рәвештә формалаштырыла һәм «Электрон бюджет» системасында Вәкаләтле орган (ул вәкаләт биргән зат) җитәкчесенең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, шулай ук бердәм порталда аңа имза салынган көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча һәм, Вәкаләтле органның рәсми сайтында сайлап алуда җиңүчене билгеләгән көннән соң килгән 14 календарь көннән дә соңга калмыйча, урнаштырыла.

Беркетмәгә түбәндәге белешмәләр керә:

- гаризаларны карап тикшерү көне, вакыты һәм урыны;

- гаризалары карап тикшерелгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

- гаризаларны кире кагу сәбәпләрен, шул исәптән мондый гаризаларның сайлап алу уздыру турындагы игъланның кайсы нигезләмәләренә туры килмәвен күрсәтеп, гаризалары кире кагылган сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

- килешү төзелә торган субсидия алучының исеме һәм аңа бирелә торган субсидиянең күләме.

Сайлап алу нәтиҗәләрен ясау беркетмәсенә үзгәрешләр кертү, мондый үзгәрешләрне кертү сәбәпләрен күрсәтеп, аны формалаштыруның әлеге пунктта билгеләнгән тәртибенә охшаш тәртиптә күрсәтелгән беркетмәнең яңа версиясен формалаштыру юлы белән сайлап алу нәтиҗәләрен ясау беркетмәсенең беренче версиясе имзаланган көннән алып 10 календарь көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

29. Сайлап алу нәтиҗәләре буенча Вәкаләтле орган тарафыннан сайлап алуда җиңүче билгеләнгәннән соң, Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсе әмере белән билгеләнгән типлаштырылган форма нигезендә сайлап алуда җиңүче белән календарь көннәрдә исәпләнә торган ун көн эчендә килешү төзелә.

Килешү «Электрон бюджет» системасында электрон документ формасында төзелә һәм һәр як исеменнән эш итәргә хокукы булган затларның көчәйтелгән квалификацияле имзасы белән имзалана.

30. Килешү түбәндәге нигезләмәләрне үз эченә алырга тиеш:

- килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирүнең мөмкин булмавына китергән бюджет акчаларын алучы буларак төп бүлүчегә бюджет йөкләмәләренең алдан билгеләнгән лимитлары киметелгән очракта, килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки яңа шартлар белән ризалашмаганда килешүне өзү турында;

- субсидия алучының, субсидия алучылар белән төзелгән килешүләр нигезендә акча алучы затларның (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләрдән, хуҗалык ширкәтләреннән һәм аларның устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында җәмгыятьләрдән, аларның устав (җыелма) капиталларында мондый ширкәтләр һәм җәмгыятьләр катнашында коммерция оешмаларыннан тыш) үзләренә карата Вәкаләтле орган тарафыннан субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәүне, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә муниципаль финанс

контроле органнары тарафыннан субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәүне тикшерүгә ризалыгы турында;

- югары технологияле чит ил җиһазларын, чималын һәм комплектлаучы эшләнмәләрне сатып алганда (алар белән тәэмин иткәндә) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән, шулай ук әлеге акчаларны бирү нәтиҗәләренә ирешү белән бәйле Тәртип белән билгеләнгән башка операцияләрдән тыш, Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетыннан алынган акча хисабына субсидия алучылар – юридик затлар, шулай ук субсидия алучылар белән төзелгән килешүләр нигезендә акча алучы башка юридик затлар тарафыннан чит ил валютасы алуны тыю турында;

Кирәк булган очракта, Вәкаләтле орган субсидия алучы белән килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

Юридик зат булган субсидияне алучыны кушу, кушылу яки үзгәртеп кору рәвешендә үзгәртеп оештырганда, килешүгә, хокуклар күчә торган юридик затны килешүдә күрсәтеп, килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән йөкләмәдә затны алмаштыру өлешендә үзгәрешләр кертелә.

Юридик зат булган субсидия алучыны бүлү, бүлеп чыгару рәвешендә үзгәртеп оештырганда, шулай ук юридик зат булган субсидия алучы юкка чыгарылганда, берьяклы тәртиптә килешүне өзү турында хәбәрнамә һәм, субсидия алучы тарафыннан үтәлмәгән, финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган йөкләмәләр һәм субсидиянең файдаланылмый калган өлешен тиешле бюджетка кире кайтару турында мәгълүматны күрсәтеп, килешү буенча йөкләмәләрне үтәү турында акт формалаштырып, килешү өзелә.

31. Сайлап алу җиңүчесенең сайлап алуны уздыру турында игъланда күрсәтелгән таләпләргә туры килмәү факты яисә сайлап алу җиңүчесенең дөрес булмаган мәгълүматны тәкъдим итүе ачыкланган очракта, Вәкаләтле орган сайлап алу җиңүчесе белән килешү төзүдән баш тарта.

32. Субсидия алучы, сайлап алуны уздыру турында игълан иткәндә күрсәтелгән вакыт эчендә, субсидияләр алучы исеменнән эш итәргә хокукы булган зат тарафыннан килешүгә имза салуны тәэмин итмәгән очракта, килешү төзүдән баш тарткан дип танылa.

33. Субсидия Вәкаләтле органга субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүдә билгеләнгән формалар буенча тапшырылган түбәндәге документлар нигезендә ай саен бирелә:

- субсидия алуга гариза;

- хисап ае өчен алынмаган керемнәрне каплауга субсидия күләме исәпләү (белешмә-хисап);

- Россия Федерациясе законнары нигезендә документлар тапшыру көненә кадәр 30 календарь көннән артык булмаган вакыт эчендә барлык дәрәҗәләрдәге Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар һәм җыемнар буенча үтәү вакыты җиткән бурычлары булмавын раслый торган документларның күчермәләре. Бурычы булган очракта, гариза бирүче әлеге бурычны гариза бирү көненә тулысынча каплавы турындагы түләү йөкләмәләре күчермәләрен бирергә хокуклы;

- субсидия бирү аена кадәр килә торган хисап ае өчен йөртелгән ташламалы категориядәге гражданнарның санын (транзакция) раслый торган Казан шәһәренең шәһәр пассажирлар транспортында йөрү өчен түләүнең автоматлаштырылган системасы агенты хисабы.

Тапшырылган документларның күчермәләре субсидия алучы тарафыннан таныкланырга һәм мөһер куелган (булган очракта) булырга тиеш.

34. Каплау өчен субсидия җибәрелә торган алынып бетмәгән керемнәр юнәлешенә транспортның һәр төре буенча 50 һәм аннан да күбрәк йөрүгә каралган озак вакыт кулланылыштагы билетлар белән түләү өчен Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты карары белән билгеләнгән тариф буенча аерым категориядәге гражданнар йөрүе өчен түләүдән алынган керем белән ташламалы транспорт карталарын һәм ташламалы балалар транспорт карталарын тулыландырудан алынган транспорт оешмасының әлеге Тәртипнең 41 пунктында билгеләнгән формула буенча исәпләнә торган кереме арасындагы аерма керә.

35. Вәкаләтле орган әлеге Тәртипнең 33 пунктында күрсәтелгән документларны терки һәм документларны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә аларны карый һәм субсидия бирү турында яисә субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә. Субсидия бирү турындагы карар субсидия бирү турындагы килешүдә билгеләнгән форма буенча рәсмиләштерелә.

36. Вәкаләтле орган:

- субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә субсидия алучылар тарафыннан Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яисә кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап счетларына үз шәхси счетыннан акчалар күчерүне гамәлгә ашыра;

- агымдагы финанс елының декабрь аена субсидия агымдагы финанс елының 31 декабренә кадәр, агымдагы финанс елының ноябре өчен тиешле субвенцияләр күләмендә, әлеге Тәртипнең 33 пунктында күрсәтелгән, тапшырылган белешмәләр, исәп-хисаплар буенча Вәкаләтле орган тарафыннан күчерелә.

Агымдагы финанс елының декабренә бирелгән субсидияләр шул айда оешмаларга тиешле субсидияләрдән артып киткән очракта, арткан сумма Вәкаләтле органга кайтарылырга тиеш.

Агымдагы финанс елының декабренә бирелгән субсидияләр күрсәтелгән чорга оешмаларга тиешле субсидияләрдән азрак булган очракта, җитмәгән сумма Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 20 мартындагы 210 номерлы «Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы территориясендә аерым категориягә караган гражданнарга җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субсидияләр бирү тәртибен раслау турында»гы карары нигезендә Вәкаләтле орган тарафыннан агымдагы елның 31 гыйнварына кадәр күчерелә.

37. Субсидия бирүне кире кагу турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

- субсидия алучы тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 33 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яисә күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

- субсидия алучы тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмау фактын билгеләү.

38. Субсидия бирү нәтиҗәсе – җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалану мөмкинлеген тәэмин итү белән бәйле рәвештә аерым категориягә караган гражданнарны бердәм электрон исемле социаль юл билетлары (ташламалы транспорт картасы) буенча йөртүдән алынып бетмәгән керемнәрен каплау.

39. Субсидия бирү нәтиҗәлелеге күрсәткече булып айлык бердәм социаль юл билетлары һәм айлык бердәм балалар социаль юл билетлары булган пассажирларны ташламалы юл йөрү белән тәэмин итү (алга таба – нәтиҗәлелек күрсәткече) тора.

40. Субсидия алучы «Электрон бюджет» системасында субсидия бирү турында килешүдә билгеләнгән форма буенча квартал саен нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешү турында хисапны хисап кварталыннан соң килә торган айның 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, еллык хисапны субсидия бирелгән елдан соң килә торган елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча тапшыра.

Вәкаләтле орган субсидия алучы тарафыннан хисаплар бирелгән көннән алып биш эш көне эчендә хисапларны кабул итүне һәм аларны тикшерүне башкара.

41. Субсидия күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

К = Птр.орг. х Т - Втр.орг., биредә:

К – ташламалы транспорт карталары һәм балалар өчен ташламалы транспорт карталары буенча гражданнарга транспорт хезмәтләре күрсәтүгә бәйле рәвештә оешмалар субсидиясе күләме;

Птр.орг – ташламалы транспорт картасы һәм балалар өчен ташламалы транспорт картасы буенча оешманың пассажирлар транспортында хисап аенда башкарылган юл йөрү саны (хисап аена юл йөрү өчен түләүнең автоматлаштырылган системасы операторы мәгълүматлары буенча транзакцияләр саны);

Т – шәһәр эчендә пассажирлар йөртүгә гамәлдәге тариф, ташламалы транспорт картасы һәм балалар өчен ташламалы транспорт картасы белән йөргән өчен түләгәндә, транспортның һәр төре буенча 50 һәм аннан да күбрәк йөрүгә каралган озак вакыт кулланылыштагы билетлар белән түләү өчен Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты карары белән билгеләнгән тарифлар кулланыла;

Втр.орг. – транспорт оешмасының ташламалы транспорт карталарын һәм балалар өчен ташламалы транспорт карталарын тулыландырудан алынган кереме, ул түбәндәге формула буенча билгеләнә:

Втр.орг. = В х Птр.орг. / Побщ., биредә:

В – ташламалы транспорт карталарын һәм балалар өчен ташламалы транспорт карталарын тулыландырудан алынган керем, ул тулыландырылган ташламалы транспорт карталары һәм балалар өчен ташламалы транспорт карталары саныннан һәм ташламалы транспорт картасын тулыландыруның билгеләнгән бәясеннән һәм балалар өчен ташламалы транспорт картасы бәясеннән чыгып билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

В = Цв х Рв + Цд х Рд, биредә:

Цв – ташламалы транспорт картасын тулыландыру бәясе;

Рв – гамәлдәге (тулыландырылган) ташламалы транспорт карталары, берәмлекләр саны;

Цд – балалар өчен ташламалы транспорт картасын тулыландыру бәясе;

Рд – гамәлдәге (тулыландырылган) балалар өчен ташламалы транспорт карталары саны, берәмлек;

Побщ. – хисап чоры өчен барлык транспорт оешмалары маршрутларындагы транспорт чарасында ташламалы транспорт карталары һәм балалар өчен ташламалы транспорт карталары транзакцияләренең гомуми саны.

42. Субсидияләр сайлап алуда җиңүчеләр арасында әлеге Тәртипнең 2 пунктында каралган максатка агымдагы финанс елына Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләре тулысынча бүленгәнче гаризалар бирү чираты тәртибендә бүленә.

43. Субсидия алучы тарафыннан субсидияләр биргәндә билгеләнгән шартлар үтәлмәгәндә, шул исәптән шартларның үтәлмәве Вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс контроле органы үткәргән тикшерү фактлары буенча ачыкланган очракта, бирелгән субсидия Вәкаләтле органның тиешле таләбен алган көннән алып 30 эш көне эчендә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты кеременә тулы күләмдә кире кайтарылырга тиеш.

44. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты керемenә акчаларны үз теләге белән кире кайтарудан баш тарткан очракта, алар Вәкаләтле орган тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә 30 көн эчендә мәҗбүри тәртиптә түләттерелергә тиеш.

45. Югары технологияле чит ил җиһазларын, чималын һәм комплектлаучы эшләнмәләрне сатып алганда (алар белән тәэмин иткәндә) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән, шулай ук әлеге акчаларны бирү нәтиҗәләренә ирешү белән бәйле Тәртип белән билгеләнгән башка операцияләрдән тыш, Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетыннан алынган акча хисабына субсидия алучыларга – юридик затларга, шулай ук субсидия алучылар белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы башка юридик затларга чит ил валютасы алу тыелган.

46. Субсидия алучылар, субсидияләр алучылар (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләрдән тыш) белән төзелгән килешүләр нигезендә акча алучы затлар аларга карата бюджет акчаларын баш бүлүче тарафыннан субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнары тарафыннан тикшерүне гамәлгә ашыруга һәм мондый нигезләмәләрне килешүгә кертүгә ризалыгын бирергә тиеш;

47. Россия Федерациясе законнары нигезендә Вәкаләтле орган тарафыннан субсидия алучыга карата субсидия бирү шартларын һәм тәртибен үтәү, шул

исәптән аларны бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә тикшерү үткәрелә, муниципаль финанс контроле органнары тарафыннан субсидия алучыларга карата Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә тикшерү үткәрелә.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча субсидия бирү шартларының, максатларының һәм тәртибенең үтәлешен бәяләү мөмкин булмаган очракта, урынга чыгып тикшерү үткәрелә. Субсидия алучы контроль өчен керү мөмкинлеген тәэмин итәргә, шулай ук күчмә тикшерү барышында субсидия бирүгә бәйле соралган документларны тапшырырга тиеш.

48. Субсидия акчаларын максатчан һәм нәтиҗәле файдаланган, шулай ук субсидия алу максатыннан тапшырылган документларның дөреслеге өчен җаваплылык законнар нигезендә субсидия алучыга йөкләнә.

49. Бюджет акчаларыннан файдалануны контрольдә тотуны Вәкаләтле орган башкара.